Изменения в Устав зарегистрированы
в Управлении Министерства юстиции
Российской Федерации
по Республике Татарстан
«23» марта 2020 года
Государственный регистрационный
№ RU165301172020001


РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск,
423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән
Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 21 феврале № 12

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 статьялары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен игътибарга алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары (Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы, 2018 елның 16 маендагы 21 номерлы, 2019 елның 13 февралендәге 5 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама шәһәре Мэрына (А.Р.Метшин) әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен үткәрүгә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2020 елның 21 февралендәге
12 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының
Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясында 1 өлешнең 22 пунктында «территория, бирү» сүзләреннән соң «шәһәр чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, бирү» сүзләрен өстәргә.

2. «Шәһәр Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләп торучы башка зат статусы» 32 статьясында:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән йөкләмәләрне башкарырга, чикләүләрне, тыюларны үтәргә тиеш. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, кулда булган акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда, әгәр башкасы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралмаган булса, билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, вакытыннан алда туктатыла;

б) 3.2. өлешенә «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «яки күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.2-1 өлешне өстәргә: «3.2-1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес һәм тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, шәһәр Советында, җирле үзидарәнең сайлау органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итү белән шәһәр Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазыйфадан азат итү;

3) аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү белән даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) үз вәкаләтләре тәмамланганчы шәһәр Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы, даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 3.2-2 өлеш өстәргә: «3.2-2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына әлеге статьяның 3.2-1 өлешләрендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы шәһәр Советы депутатлары хокуклы түгел:

«1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты идарәсендә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында яки съездында (конференция) катнашу;

б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәрнамә җибәреп, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты идарәсендә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында яки съездында (конференция) катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмалар һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә.».

Даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы шәһәр Советы депутаты граждан, административ яки җинаять эше буенча яисә административ хокук бозу турында эш буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнаша алмый.

Шәһәр Советы депутатлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Устав белән билгеләнә.».

3. «Яңа сайланган шәһәр Советы эшен оештыру» 34 статьясында 1 өлешнең икенче җөмләсендә «шәһәр сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «шәһәр Мэры урынбасары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

4. «Шәһәр Советы компетенциясе» 35 статьясында 1 өлешнең 35 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

5. «Шәһәр Мэры статусы» 45 статьясында 3, 4, 7 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга.

6. «Шәһәр Мэры урынбасарлары» 47 статьясында 8, 9 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга.

7. «Шәһәр башкарма комитеты вәкаләтләре» 51 статьясында:

а) 3 өлешнең 3.2 пунктында «бирә» сүзләреннән соң «шәһәр чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, бирә» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлешнең 4.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.3. билгеләнгән тәртиптә торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарны торак биналарга күчерү турында карар кабул итә, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерә, билгеләнгән тәртиптә муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннарын яшәү өчен яраксыз дип таный, күпфатирлы йортлар, барлык торак урыннар Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип таный»;

в) 5 өлешнең 5.11, 5.13 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

8. «Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе» 52 статьясында 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «11. Әлеге статьяның 10 пункты нигезендә гамәлгә ашырылган тикшерү нәтиҗәсендә шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, кулда булган акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы Президенты шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аңа карата башка дисциплинар җәза куллану турында тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка гариза белән мөрәҗәгать итә.».

9. «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе» 78 статьясында 6 өлештә сүзләрен «Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.

10. «Шәһәр бюджеты» 86 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Шәһәрдә бюджет процессын хокукый җайга салу Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шәһәр Советы карары һәм башка муниципаль хокукый актлар белән расланган шәһәрнең бюджет–финанс сәясәте турындагы нигезләмә белән гамәлгә ашырыла.».

11. 87–93 статьяларны үз көчен югалткан дип танырга.

12. «Шәһәр Уставы проектын әзерләү һәм әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе» 94 статьясында:

а) 3 өлештә «Россия Федерациясе субъекты законнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «әлеге Уставның 21 статьясы нигезендә» сүзләрен «әлеге Уставның 22 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

13. «Шәһәр Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе» 95 статьясында 4 өлешендә «, кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

Э.Р. Долотказина